**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 февралендәге 325 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 декабрендәге 5290 номерлы**
**«Казан шәһәре Киров районының Горький Шоссесы урамындагы**
**җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5290 номерлы «Казан шәһәре Киров районының Горький Шоссесы урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында гаризасын карап тикшергәннән соң, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5290 номерлы «Казан шәһәре Киров районының Горький Шоссесы урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1, 2, 3 һәм 4 номерлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталарны шул ук тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5290 номерлы карарына 1 һәм 2 номерлы кушымталар дип санарга.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә турында тиешле мәгълүматны кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан (хезмәт урынында файдалана торган материал) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чykканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 февралендәге
325 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Киров районының Горький Шоссесы урамында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб: 1:1000
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| (розовый прямоугольник) | Ачык сервитутлар (проектлана торган) |
| (контур) | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләре (гамәлдәге) |

| | |
|---|---|
| | Җир кишәрлекләре |
| | Кадастр кварталлары |
| 16:50:190402 | Кадастр кварталы |
| 16:50:190402:1350, 16:50:190402:1030 | Хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

_______________________________